## Сәхнәдә яшь артистлар...

**Безнең мәктәпнең 1-4 нче сыйныфы укучылары курчак театрын сәхндә күрсәттеләр. Алар А.Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятен һәм «Батыр әтәч» исемле татар халык әкиятен сәхнәләштерделәр..**



5нче сыйныфның рус төркемендә укучы балалар “Өч кыз” дигән татар халык әкиятен күрсәттеләр. Укучылар үзләре җырлар уйлап чыгарырга ярдәм иттеләр, бирелгән рольләрне сәнгатьле итеп башкарырга өйрәнделәр. Әкият бик кызыклы килеп чыкты, караган укучыларда ул уңай тәэсир калдырды.




Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәренең

"Знче урта гомуми белем мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе

Мәктәп телефоны: 8855553-44-20



Татарстан Республикасы Минзәлә шәһәренең

"Знче урта гомуми белем мәктәбе" гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе


# Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы






**2021 нче ел**

## Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын ачу тантанасы.

2021 нче ел туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Бүгенге көн шартларында бу бик мөһим.

Татарстаныбызда дүрт миллионга якын кеше яши. Күпчелеген татарлар һәм руслар тәшкил итә. Шулай ук чуашлар, марилар, удмуртлар, мордвалар һ.б. милләт вәкилләре дә бар. Безнең мәктәптә дә төрле милләт балалары укый: руслар, татарлар, марилар, таҗиклар, украиннар, әрмәннәр. Алар үзләренең телләрен камил беләләр, шуңа да бу бәйрәмдә үз телләрендә исәнләшеп, телләр турында кызыклы сүзләр әйттеләр. Күп кенә милләт укучылары татар телен дә теләп өйрәнәләр. Алар татар телендә шигырьләр, җырлар беләләр, биюләр башкаралар, уеннар уйныйлар.









## Рәсәй халыкларының фестивале

Районыбызда инде икенче ел рәттән Рәсәй халыкларының фестивале үткәрелә. Анда төрле мәктәп укучылары һәм укытучылары чыгыш ясый ала. Фестивальдә бер милләт вәкилләренең йолалары, бәйрәмнәре турында сәхнәләштерү әзерләргә кирәк. Быелгы чарада башлангыч сыйныфлары актив катнашты. Алар номинациядә җиңүчеләр булдылар.

### «Халыклар дуслыгы» темасына күргәзмә.

Мәктәптә күргәзмә эшләде. Ул укучылар, әти-әниләр һәм укытучылар ярдәме белән оештырылды. Күргәзмәдәге һәр экспонат игътибарга лаек,чөнки аны күп тырышлык белән ясаганнар. Шулай ук бу ясалган әйберләр шәһәребезнең ярминкәләрендә дә күрсәтелде һәм сатылды.

### «Карга боткасы» уены.



Башлангыч сыйныфы укучылары өчен карга боткасы үткәрелде. Укучылар каргаларга ботка бирделәр, төрле уеннарда катнаштылар..Бәйрәм бик күңелле үтте.



Дәрестән соң укучыларыбыз да кул эшләре ясау белән шөгыльләнәләр. Алар бу истәлекле елны каршылап, төрле өй кирәк– яраклары әзерлиләр, уенчыклар ясыйлар һәм аларны милләт орнаментлары белән бизиләр.



### «Сабан туе»

Милли бәйрәмебез Сабантуйны да үткәрү - укучылар өчен көтеп алынган көн, чөнки бу бәйрәмдә төрле бәйгеләрдә катнашып бүләкләр алырга була. Җыр- бию дә күңелне күтәрә .



Төр- ле чаралар



